DOI: 10.26907/2311-2042-2023-21-2-189-195

# REVIEW OF MARCEL BAKIROV’S BOOK “MEN DE BER FIKER” (“A THOUSAND AND ONE THOUGHTS”) (KAZAN: “KHALKYBYZ MIRASY” PUBLISHING HOUSE, 2023. 536 P.)

**Flera Sagitovna Sayfulina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
Flera.Sajfulina@kpfu.ru.

The purpose of the article is to convey to the reader the essence of Marcel Bakirov’s book “Men de ber fiker” (“A Thousand and One Thoughts”) and to determine the place of the book, chosen as our research object, in the field of literary criticism and folklore. The article establishes the author’s purpose of writing this philosophical-sounding book and its target readers.

The article highlights the scientific value of this voluminous book, consisting of three chapters, and proves that the individual articles, presented in the chapters, describe various aspects of the scholar’s work, they are compiled in a logical sequence, forming a single whole.

The research articles, presented in the first two chapters of the book, help to understand the work of the prominent scholar who has lived a long and hard life, who is conducting studies in the field of literary criticism, the history of poetry and folkloristics. The third chapter expresses the author’s desire to transfer research results to other scholars, to be loyal to the chosen profession and reveals the secrets of achieving great success. It is proven that such work is very important for aspiring young scholars.

**Key words**: Marcel Khaernasovich Bakirov, folklore studies, literary studies, history of poetry

A reader who will pick up this book should undoubtedly see that its author, Marcel Bakirov, is a famous literary critic, folklorist, the author of a dozen monographs and numerous other research works.The mentioned works were perceived by the scientific community as a new word, a discovery in literary criticism, in explaining the essence of Tatar oral folk art. During Marcel Bakirov’s presentation of his dissertation for the candidate of philology degree (1972), in addition to the members of the academic dissertation council, there were prominent figures of the Tatar people present, among them Naki Isanbet, Baki Urmanche, Mukhammat Gainullin, Gazi Kashshaf and Khasan Tufan, which testified to the interest that his work aroused. The work of the young man, who had just embarked on the scientific path, was highly appreciated. Positive reviews of the dissertation came from the famous Turkologist A. Shcherbak, the famous scholar, Professor of Leningrad University Gabdrakhman Tagirzyanov, the expert in aruz (theory of versification) from Azerbaijan Akram Jaffar, the scholar studying the structure of the poem, Professor from Kazakhstan Zaki Akhmetov, the Uyghur scholar Morat Khamraev, the Uzbek scholar Uzbek Tuychiev and the Bashkir scholar Gaisa Khusainov. The first opponent, the honored scholar Gali Khalit, evaluating the dissertation, pointed out that M. Bakirov’s work was completed at the level of a doctoral dissertation, which proved the high scientific potential of the young scholar, testifying to the fact that an accomplished scholar had entered the Tatar language studies.

M. Bakirov’s book “Men de ber fiker” (“A Thousand and One Thoughts”) begins in an unusual way: with his poem “Zhanym erner yeshep tuimaganga” (“My Heart Will Ache because I Have Not Lived Enough”), proposed by the author instead of an introduction. These lines can be perceived as a poetic appeal of the scholar who has devoted his life and its meaning to the harmony of the poetic word and is now ready to convey it to the reader. The philosophy of life, his experiences and the hopes of the person, who over the course of almost a century has gone through many life’s trials and tribulations, but has devoted his entire life to literary criticism, who considers that the majestic “key to the mind,” is contained in the following poetic lines:

Chorlar kumgen katlamnarda (In layers buried for centuries,)

Ene belen koe kazydym. (I dug a well with a needle)

Ezene toshrem erak babamnarnyn, (I joined the trail of my distant grandfather)

Chongyllarda mayak kabyzdym. (I lit a beacon in the abyss)

Tik sutelmi kala akhyrgacha (It just doesn't turn around, it stands its ground)

Uzem zyigan serler yomgagy. (A bundle of secrets collected by myself)

Bez – fanatik mogikannar kitkech, (When we Mohican fanatics leave,)

Tamchydan kul yasar kem tagy?! (Who else will make a lake out of drops??!)

This voluminous book is printed in three chapters, divided according to the purpose of the work.

The first chapter, called "Atakly hem tanylgan shekheslerebez". (Retsenziyeler, izhat portletlary, ocherklar (p. 5) ("Respected and Famous People" (Reviews, creative portraits, essays (p. 5)), introduces the reader to the work of almost 30 famous personalities who have earned recognition in the literary art of the Tatars. Introduction to Tatar poetry, starting from the work of Utyz-Imeni, Gabdelzhabbar Kandaly and to modern poets Renat Kharis, Muhammad Mirza and Elmira Sharifullina, makes it possible to clearly present its development. The scholar, who identifies the poet's work as the object of his study, in our opinion, has managed to skillfully find a key word, a concept that is akin to a symbol, which determines the essence of this poet's work. In the definition of M. Bakirov, for example, Utyz Imeni is "paving the way from stagnation to renewal", Gabdelzhabbar Kandaly is "the poet who has brought love from heaven to earth", the Honored Scientist, playwright N. Isanbet is "People's Academician Naki Isanbet". Thus, the title of the article itself helps to understand the value of the work, the creative power of the individual that will be discussed. With the help of this "key", the author prepares the student for comprehending the article. Further articles follow: "Shigri suz kuetnen sere" ("The Poetic Word is the Secret of Power") (110 years have passed since the birth of Musa Jalil), "Shigyr garmoniyase" ("Harmony of a Poem") (Review of the book of the same name by Nail Yuziev), "Fen korable kapitany" ("The Captain of the Ship of Science") (Creative and social portrait of Mansur Khasanov), "Chyn galim hem pedagog" ("Real Scholar and Teacher") ("In connection with the 70$^{th}$ anniversary of Rezeda Ganieva"), etc. When revealing the creative power of the Tatar poets and presenting their beautiful works, the scholar skillfully selects metaphors and epithets: for example, the article, dedicated to the work of Renat Kharis, is titled "Shigyr zhandyr, shigyr kandyr" ("A Poem Is the Soul, a Poem Is Blood"), the article dedicated to the 75$^{th}$ anniversary of the poet Delfat Malikov's birth is called "Elanny sairatkan Zelfet fenomeny" ("The Phenomenon of Zulfat, Who Made the Snake Sing"), the article about the work of Kharras Ayup has the name "Doldolne iyerlegen shagyir" ("The Poet, Riding a Winged Fairytale Horse"), the article about the work of Muhammad Mirza is given with an explanation of the witty conclusions in his works and is called instructively, like in folk sayings, "Akyl achkychy is suz" ("The Key to the Mind Is the Word"). In addition, this chapter contains the articles "Katarsis tudyra aluchy shagyire" ("The Poetess Capable of Producing Catharsis") (based on the work of Elmira Sharifullina), "Igelekle irne il onytmas!" ("The Country Will Not Forget a Grateful Man") (dedicated to the work of Shaikhelislam Sadretdinov), "Monga torelgen mogzhiza" ("A Miracle Wrapped in Melody") (about the singer Gulzada Safiullina), "Altyn kully superkhirurg" ("Super Surgeon with His Hands Made of Gold") (about our compatriot, doctor Ravil Shaimardanov) and others, full of the author's admiration for the people who have reached heights in their fields.

In the second chapter of the book (Izhadi mirasybyz ezlerennen. (Fenni ezlenuluremnen ber tematik torkeme)) (In the Footsteps of Our Creative Heritage. (One Thematic Group of My Scientific Research)), a number of research articles are presented, they are dedicated to the problems in the field of folklore. This chapter contains M. Bakirov's articles on the development of Tatar folk art, the diversity of genres, the essence of national holidays; they show the roots of the Tatar poem and discuss the issues of teaching these spiritual values at school. These works, based on deep scientific analysis and generalizations, help to understand the trends of the scholar's research and the results of his scientific studies.

The third chapter of the book "Shekhesem hem fenni eshchenlegem turynda" (Zamandashlarymnyn beyelemelerennen kayber urnekler, p. 419) ("About My Personality and Research Work (Some examples from the reviews of my contemporaries, p. 419)") is especially important for a young reader seeking to understand the great scholar's work. The chapter begins with an article by Doctor of Philology, Prof. Anvar Sharipov, "Shundyi tatar tyurkology bar" ("There Is Such a Tatar Turkologist") (Kazan utlary, 2013, No. 12). This work is rightfully placed here,

because it describes the entire life of the future scholar from his childhood until the time when he became an accomplished scholar. An instructive story about the fate of the scholar's parents, about his childhood experiences, his sincere aspirations and hard work, his endless quests and, despite everything, his ability to achieve his goals, helps to understand Marcel Bakirov's path to Tatar science and the scientific essence of his works.

We believe that for young scholars, for those who want to reach heights in science, the second article in this chapter will be of special interest. Titled "Izvlecheniya iz otzyvov doktorskoi dissertatsii Bakirova M. Kh." (Tema dissertatsii: "Genezis i drevneishie formy obshchetyurkskoi poehzii") ("Extracts from reviews of M. H. Bakirov's doctoral dissertation " (the dissertation topic is "Genesis and ancient forms of common Turkic poetry")), the article presents excerpts from reviews of Marcel Bakirov's doctoral dissertation. Here, the views of distinguished scholars on M. Bakirov's work are given, the scientific novelty of the dissertation is indicated and the valuable findings in the area of his research are assessed. In the reviews of the Academy of Sciences of Tatarstan, its member M. Khasanov, Academician of the Bashkortostan Academy of Sciences G. Khusaenov and Professor of Yakut University N. Toburakov, this dissertation is assessed as an important, complete, comprehensive and epoch-making work, which has laid the foundation for a new scientific trend, studying the genetic-evolutionary development of Turkic poetry.

The article "Shigri zhan ahene" ("Poetic Spiritual Harmony") ("Kazan utlary", 2009, No. 9) was written by Doctor of Philology, Professor of Kazan University Talgat Galiullin, a scholar who studied the trends of Tatar poetry; it was written during the celebration of Marcel Bakirov's 75$^{th}$ anniversary, and it had the form of a review of the scholar's textbook for universities "Tatar folklory" ("Tatar Folklore") ("Magarif", 2008), which was published at that time. In the article, the author defines the relevance of this work as follows: "Despite the fact that we were constantly collecting folklore, carrying out practical and research work, we felt the need for serious research work that would reveal the philosophical, aesthetic value and immortality of this wealth, determining the prospects for scientific research, the work that could become a textbook for educational institutions. In this regard, the publication of the book by M. Bakirov has become a particularly significant event". The article describes the structure of the book, notes its value in terms of defining folklore genres and other aspects.

The article by Mansur Khasanov, the President of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan "Bu kader tirenge bereunen de utep kergene yuk ide ele" ("No One Has Ever Reached So Deep"), the very title of which reveals the essence of the article, proves the importance of Marcel Bakirov's works, the depth of his thought, the value of his discoveries. The emphasis is placed on the fact that the ideas of the scholar have a theoretical and practical basis; they are based on related sciences – poetics, art history, aesthetics, philosophy, ethnography, history, archeology, cultural studies, etc. This chapter also contains the words said about Marcel Bakirov's personality and his works by the scholar Rifa Rahman, writer Marcel Galiev, linguist Gumer Sattar-Mullile, writer Foat Sadriev, historian Rafael Muhammetdinov, folklorist Fanzili Zhaukharova, Academician Indus Tagirov and others.

Thus, this book, "A Collection of Articles Dedicated to the 90$^{th}$ Anniversary of Prof. Marcel Bakirov", indeed, as the compilers note, has achieved its goal: the publication helps to understand the essence of the scholar's work and the stages of his career in science.

# МАРСЕЛЬ БАКИРОВНЫҢ «МИН ДӘ БЕР ФИКЕР» (КАЗАН: «ХАЛКЫБЫЗ МИРАСЫ» НӘШРИЯТЫ, 2023. 536 б.) КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Флера Сәгыйть кызы Сәйфулина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Flera.Sajfulina@kpfu.ru

Тәкъдим ителгән мәкалә Марсель Хәернас улы тарафыннан төзелгән «Мең дә бер фикер» дип аталган китапның асылын ачыклауга һәм укучыга җиткерүгә юнәлтелгән. Тикшерү – бәяләү объекты итеп алынган хезмәтнең исеме әдәбият гыйлеме, фольклористика фәне өлкәләрендә танылган галим эшчәнлегендә нинди урын тотуын, әлеге фәлсәфи яңгырашлы исемле китапның авторы тарафыннан нинди максатта, кайсы укучыны күз алдында тотып төзелүен ачыклаудан гыйбарәт.

Мәкаләдә өч бүлектән торган әлеге саллы китапның фәнни кыйммәте ачыклана, бүлекләрдә тәкъдим ителгән аерым мәкаләләрнең галим эшчәнлегенең төрле юнәлешләрен чагылдырып, үзенчәлекле бербөтенне тәшкил итәрлек эзлеклелектә, эчке логикага нигезләнеп төзелгән булуы дәлилләнә.

Китапның алдагы ике бүлегендә тәкъдим ителгән фәнни мәкаләләр – озын гомер юлын үткән, катлаулы вакыйгаларны кичергән олпат галимнең әдәбият белеме, шигърият тарихы, фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеген шактый тулы күзалларга ярдәм итә. Өченче бүлекнең кыйммәте исә – галим эшчәнлегенең, фәнгә, сайлаган һөнәргә тугры булуның нәтиҗәсен, олы уңышка ирешүнең серләрен күрсәтүдә дип бәяләнә. Мондый хезмәтнең фән өлкәсендә тәүге адымнарын атлаучы яшь буын өчен аеруча бәһале булуы раслана.

**Төп төшенчәләр**: Марсель Хәернас улы Бакиров, фольклористика, әдәбият гыйлеме, төрки шигырь тарихы

«Мең дә бер фикер» дип аталган әлеге китап олпат галим тарафыннан үзенең 90 еллык олы юбилеен билгеләп үтергә әзерләнгән көннәрдә бастырыла. Димәк, әлеге басманы галимнең тормыш һәм эшчәнлегенең аерым бер чорына билгеле бер йомгагы, нәтиҗәсе дип тә карарга мөмкин.

Китапны кулына алган укучы, әлбәттә, аның авторы – Марсель Бакировның җитмешенче еллардан башлап, бер-бер артлы дөнья күргән күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы, танылган әдәбият галиме, фольклорчы, тюрколог булуын күз алдында тотарга тиеш. Аның хезмәтләре фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан әдәбият гыйльмиятендә, татар халык авыз иҗатының асылын аңлатуда яңа сүз, ачыш буларак кабул ителде. Марсель Бакировның кандидатлык диссертациясен яклау утырышында (1972 ел) гыйльми яклау советы әгъзаларыннан тыш, татарның асыл шәхесләре, шул исәптән Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мөхәммәт Гайнуллин, Гази Кашшаф, Хәсән Туфан кебекләрнең катнашуы гына да фән юлына баскан ир-егетнең әлеге хезмәтенә никадәр зур игътибар, кызыксыну булуы турында сөйли. Диссертациягә танылган тюрколог А.М. Щербак, Ленинград университеты профессоры, күренекле галим Габдрахман Таһирҗанов, Азәрбайҗаннан гаруз белгече Әкрәм Җәффар, Казахстаннан шигырь төзелешен өйрәнүче галим, профессор Зәки Әхмәтов, уйгыр галиме Морат Хамраев, үзбәк галиме Үзбәк Туйчиев, башкорт галиме Гайсә Хөсәеновларның уңай фикере, диссертациягә бәя бирүче беренче оппонент, атаклы галим Гали Халитнең М. Бакиров хезмәтенең докторлык диссертациясе дәрәҗәсендә башкарылган булуына басым ясавы – яшь галимнең фәнни потенциалы зурлыгын раслый, татар сүз сәнгатен гыйльми өйрәнүгә җитлеккән галим килүе хакында сөйли.

Аннан соң илле ел вакыт узган, фән дөньясында беренче ачышларын ясаган яшь галим исә фәнни эшчәнлеге белән төрки дөньяга танылган олуг шәхес, олпат галим булып җитлеккән.

М. Бакировның әлеге китабы кötелмәгәнчә, авторның кереш урынына тәкъдим иткән «Җаным әрнер яшәп туймаганга» дип аталган шигыре белән башлана. Әлеге юллар галимнең поэтик мөрәҗәгате, үз тормышы-яшәешенең асылын, кредосын, мәгънәсен шигъри сүз

гармониясенә салып, укучыга җиткерүе дип кабул ителергә хаклы. Гасырга якын тормыш юлында катлаулы сынауларны үтеп, гомерен әдәбият фәненә хезмәт итүгә багышлаган, галиҗәнап сүзне – «акыл ачкычы» дип санаган шәхеснең яшәү фәлсәфәсе, борчулары, өмете түбәндәге шигырь юлларына салынган:

Чорлар күмгән катламнарда
Энә белән кое казыдым.
Эзенә төштем ерак бабамнарның,
Чоңгылларда маяк кабыздым.

Тик сүтелми кала ахыргача
Үзем җыйган серләр йомгагы.
Без – фанатик могиканнар киткәч,
Тамчыдан күл ясар кем тагы?!

Әлеге саллы китап авторның максатына ярашлы өч зур бүлеккә туплап тәкъдим ителгән.

«АТАКЛЫ ҺӘМ ТАНЫЛГАН ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ». (РЕЦЕНЗИЯЛӘР, ИҖАТ ПОРТРЕТЛАРЫ, ОЧЕРКЛАР [5 б.] дип исемләнгән беренче бүлек укучыны татарның әдәбият-сәнгатендә танылу алган өч дистәгә якын шәхесе иҗаты белән таныштыра. Утыз-Имәни, Габделҗаббар Кандалыйлардан башлап, замана шагыйрьләреннән Ренат Харис, Мөхәммәт Мирза, Эльмира Шәрифуллина иҗатына кадәр күзәтү – татар шигърияте үсешен шактый эзлекле күзалларга мөмкинлек бирә. Үзе өйрәнү объекты итеп алган әдип иҗатын ачуда, галим, безнеңчә, бик оста рәвештә әлеге шагыйрьнең иҗат асылын билгеләрлек ачкыч сүз – символ дәрәҗәсендә торырлык гыйбарә, асыл сүзне таба алган. М. Бакиров билгеләмәсендә, мәсәлән, Утыз Имәни – «Торгынлыктан яңарышка юл яручы», Габделҗаббар Кандалый – «Мәхәббәтне күктән җиргә төшергән шагыйрь», халкыбызның атаклы галиме, драматург Н. Исәнбәт исә – «Халык академигы Нәкый Исәнбәт». Шул рәвешле, хәтта мәкалә исеме дә алда сүз алып барылачак шәхеснең эшчәнлеген, иҗатының, хезмәтләренең кыйммәтен аңларга ярдәм итә, автор әлеге «ачкыч» ярдәмендә укучыны мәкаләне аңларга әзерли. Алга таба «Шигъри сүз куәтенең сере» (Муса Җәлилнең тууына – 110 ел), «Шигырь гармониясе» (Нил Юзиевның әлеге исемдәге китабына бәяләмә), «Фән корабле капитаны» (Мансур Хәсәновның иҗат һәм социаль портреты), «Чын галим һәм педагог» (Резеда Ганиеваның 70 яшьлеге уңае белән) һ.б. хезмәтләре тәкъдим ителә. Татар поэзиясенең асыл үрнәкләрен тудырган авторлар иҗатын ачканда, галим шагыйрьләргә тиң метафора, эпитет остасына әверелә: мисалга, «Ренат Харис иҗатына аналитик караш» дигән аңлатма белән бирелгән мәкаләнең исеме «Шигырь җандыр, шигырь кандыр» дип тәгаенләнгән, шагыйрь Дөлфәт Маликовның тууына 75 ел уңаеннан язылган мәкалә исеме «Еланны сайраткан Зөлфәт феномены» дип бирелгән, Харрас Әюп иҗатын ачуга юнәлтелгән мәкаләсе «Дөлдөлне иярләгән шагыйрь» дип аталган, «Мөхәммәт Мирза иҗатында җор-үткен фикер сөреше» дигән аңлатма белән бирелгән язмасы халык әйтемнәрендәгечә гыйбрәтле итеп, «Акыл ачкычы – сүз» дип куелган. Болардан тыш, әлеге бүлектә «Катарсис тудыра алучы шагыйрә» (Эльмира Шәрифуллина иҗаты буенча), «Игелекле ирне ил онытмас!» (Шәйхелислам Садретдинов эшчәнлеген ачуга багышланган), «Моңга төрелгән могҗиза» (җырчы Гөлзадә Сафиуллина хакында), «Алтын куллы суперхирург» (якташы, табиб Равил Шәймәрданов турында) һ.б. мәкаләләр – үз өлкәсендә югары казанышларга ирешкән шәхесләргә карата авторның соклану тулы язмалары урын алган.

Китапның икенче бүлегендә (ИҖАДИ МИРАСЫБЫЗ ЭЗЛӘРЕННӘН. (ФӘННИ ЭЗЛӘНҮЛӘРЕМНЕҢ БЕР ТЕМАТИК ТӨРКЕМЕ)) галимнең фольклористика өлкәсендәге эзләнү проблемаларын яктыртуга багышланган фәнни юнәлештәге мәкаләләренең бер бәйләме тәкъдим ителә. Әлеге бүлектә М.Х. Бакировның татар халык авыз иҗаты үсешенә, жанрлар үзенчәлегенә, милли бәйрәмнәребезнең асылын өйрәнүгә, татар шигыренең тамырларын ачыклауга, әлеге рухи кыйммәтләрне мәктәптә укыту мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре тупланган. Тирән фәнни эзләнүләргә, гомумиләштерүләргә нигезләнгән милли мәдәният-сәнгатебезнең аз өйрәнелгән, бәхәсле һәм четерекле якларын өйрәнүгә юнәлтелгән әлеге хезмәтләр галимнең гыйльми эшчәнлегенең юнәлешләрен, фән өлкәсендәге киңкырлы эзләнүләре нәтиҗәләрен күзалларга ярдәм итә.

Китапның «ШӘХЕСЕМ ҺӘМ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕМ ТУРЫНДА» (ЗАМАНДАШЛАРЫМНЫҢ БӘЯЛӘМӘЛӘРЕННӘН КАЙБЕР ҮРНӘКЛӘР, [419 б.] дип аталган өченче бүлеге – олпат галимнең эшчәнлеген аңларга омтылган яшь укучы өчен аеруча әһәмиятле. Бүлек филология фәннәре докторы, профессор Әнвәр

Шәриповның «Шундый татар тюркологы бар» («Казан утлары», 2013, №12) дип аталган мәкаләсе белән ачыла. Әлеге хезмәтнең нәкъ шушы урында бирелүе акланган, чөнки монда булачак галимнең гомер сукмагы бала чагыннан алып, олуг галим булып җитлеккәнчегә кадәр күздән кичерелә. Галимнең ата-анасы язмышы, бала чагында кичергәннәре, самими омтылышлары, якты хыялларының тырыш хезмәт, туктаусыз эзләнүләр, бернигә карамыйча, максатка ирешүе хакындагы гыйбрәтле кыйсса – Марсель Хәернас улының татар фәненә килү юлын һәм хезмәтләренең гыйльми асылын аңларга мөмкинлек бирә.

Яшь галимнәр, гыйльми биеклекләргә ирешергә хыялланучылар өчен бүлектә тәкъдим ителгән икенче язма кызыклы булыр дип уйлыйбыз. «Извлечения из отзывов докторской диссертации Бакирова М.Х.» (Тема диссертации: «Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии») дип аталган баш астындагы язмалар Марсель Бакировның докторлык хезмәтенә бәяләмәләрдән сөземтәләр рәвешендә бирелгән. Монда атаклы галимнәрнең М.Х. Бакиров хезмәтенә карашлары, диссертациянең гыйльми яңалыгы, фән өлкәсендә кыйммәтле табышлары югары бәяләнә. Татарстан Фәннәр академиясе әгъзасы М.Х. Хәсәнов, Башкортстан Фәннәр Академиясе академигы Г.Б. Хөсәенов, Якут университеты профессоры Н.Н. Тобураковлар бәяләмәсендә әлеге диссертация җитди, җитлеккән, комплекслы, эпохаль, фәндә яңа юнәлешне башлаган, төрки поэзиянең генетик-эволюцион үсеш нигезләрен ачкан кыйммәтле хезмәт буларак бәяләнә.

Татар шигъриятенең үсеш тенденцияләрен җитди фәнни нигездә өйрәнүче галим, филология фәннәре докторы, профессор, Казан университеты галиме Тәлгат Галиуллинның «Шигъри җан аһәңе» («Казан утлары», 2009, № 9) мәкаләсе Марсель Хәернас улының 75 яшен билгеләп үткән көннәрдә галимнең шул вакытта дөнья күргән югары уку йортлары өчен тәгаенләнгән «Татар фольклоры» («Мәгариф», 2008) дәреслегенә бәяләмә рәвешендә язылган. Әлеге хезмәтнең актуальлеген мәкалә авторы түбәндәгечә билгели: «Бездә фольклорны җыю, гамәли вә фәнни өйрәнү эше даими алып барылса да, бу байлыкның фәлсәфи-эстетик бөеклеген, үлемсезлеген ачып, гыйльми тикшеренүләрнең перспективасын билгеләгән һәм уку йортлары өчен дә дәреслек булырдай бер җитди хезмәткә ихтыяҗ сизелә иде. М. Бакировның әлеге хезмәте бу җәһәттән сөенечле күренеш булды». Мәкаләдә китапның төзелеше, фольклор жанрлары төрлелеген тәкъдим итүе ягыннан кыйммәте һ.б. яклары ачыклана.

ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәновның «Бу кадәр тирәнгә берәүнең дә үтеп кергәне юк иде әле» дип аталган, исеме үк язманың асылын ачып сала торган мәкаләсе галим Марсель Бакиров хезмәтләренең җитдилеген, фикер йөртүенең тирәнлеген, ачышларының кыйммәтен раслый. Галим фикеренең фәнни-гамәли яктан нигезләнгән булуын, чиктәш фәннәргә – шигырь белеме, сәнгать гыйлеме, эстетика, фәлсәфә, этнография, тарих, археология, культурология һ.б. – нигезләнеп расланган булуына басым ясала. Әлеге бүлектә шулай ук, галимә Рифә Рахман, язучы Марсель Галиев, тел галиме Гомәр Саттар-Муллиле, язучы Фоат Садриев, тарих фәннәре галиме Рафаэль Мөхәммәтдинов, фольклорчы-галимә Фәнзилә Җәүһәрова, академик Индус Таһиров һ.б.ның Марсель ага Бакиров шәхесенә, хезмәтләренә мөнәсәбәтле фикерләре тупланган.

Шул рәвешле, әлеге китап, чыннын да, төзүчеләр тарафыннан билгеләнгәнчә, ПРОФЕССОР МАРСЕЛЬ БАКИРОВНЫҢ 90 ЯШЕ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН ҖЫЕНТЫК буларак, үз максатына ирешкән: басма галимнең эшчәнлегенең асылын аңларга, гыйльми үсеш баскычларын күзалларга ярдәм итә.

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ МАРСЕЛЯ БАКИРОВА «ТЫСЯЧА И ОДНА МЫСЛЬ» (КАЗАНЬ: ИЗДАТЕЛЬСТВО «ХАЛКЫБЫЗ МИРАСЫ», 2023. 536 с.)

**Флера Сагитовна Сайфулина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казан, ул.Кремлевская, д. 18
Flera.Sajfulina@kpfu.ru

Статья написана в жанре рецензии на сборник научных трудов М. Х. Бакирова «Мең дә бер фикер» («Тысяча и одна мысль»). Кратко охарактеризованы его разделы, очерчена целевая аудитория. Научные труды ученого позволяют сформировать представление о многогранной деятельности М. Х. Бакирова, а статьи современников – охарактеризовать его личность в многообразии его интересов, ценностных ориентиров.

**Ключевые слова**: Марсель Хаернасович Бакиров, фольклористика, литературоведение, история тюркского стиха